РАСЛЫЙМ
МАУ «Шатлык »яшьләр үзәге»
Директоры Г. Х. Ковальчук
«11» января 2021 ел

ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МАУ «ШАТЛЫК» ЯШЬЛӘР ҮЗӘГЕ
ИҖАТ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕНӘ КАБУЛ ИТҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Кагыйдәләр Яр Чаллы шәһәренең Муниципаль автоном учреждениесе «Шатлык» яшьләр үзәге Уставы нигезендә эшләнә.

1.2. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге Уставы нигезендә түгәрәкләргә, студияләргә, клубларга йөрүчеләрдән баш тарту кеше саны артык булу сәбәпле генә булырга мөмкин.

1.3. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге базасында түгәрәкләр, студияләр,шулай ук башка хезмәтләр бушлай эшлиләр.

1.4. Коллектив житәкчесенең иҗат берләшмәсенә кабул итүнеңүз кагыйдәләре була.

II. БЕРЛӘШМӘГӘ КАБУЛ ИТҮ ШАРТЛАРЫ

2.1. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәгенең түгәрәкләренә һәм студияләренә Яр Чаллы шәһәре халкы түбәндәге кагыйдәләр белән танышканнан соң кабул ителә. Балалар түгәрәккә ата-аналардан баланы кабул итү турындагы гариза нигезендә кабул ителә. Өлкәннәр шәхси гариза нигезендә кабул ителәләр.

2.2. Түгәрәкләргә һәм студияләргә кабул иткәндә,тыңлау, әңгәмә (кирәк булганда) үткәрелә.

2.3. Түгәрәкләр, студияләр, берләшмәләр сәнгать житәкчесе төзегән дәресләр челтәре буенча эшлиләр. Сәнгать житәкчесе дәресләр челтәренә, кирәк булган очракта, үзгәрешләр кертергә мөмкин. Коллектив жыю агымдагы елның 1 сентябреннән 15 сентябренә кадәр үткәрелә.

2.4. Түләүле дәресләр өчен түләү һәрбер айның 10сына кадәр башкарыла.

2.5. Бала авырган яки дәресләрнең яртысыннан күбрәгендә булмаган очракта медицина белешмәсе сорала. Бала дәрестә булмаган очракта, түләү яңадан исәпләнми.

III. ДӘРЕСЛӘРГӘ ЙӨРҮ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

3.1. Катнашучылар берләшмәләргә дәресләр челтәре нигезендә йөрергә тиеш.

3.2. Катнашучылар һәм аларны озата баручы затлар дәресләргә 15-20 минут кала килә.

3.3. Катнашучылар шөгыльләнергә килә алмаган очракта житәкчене алдан ук кисәтеп куярга тиеш. Башкалар өчен куркыныч, йогышлы авырулар вакытында дәресләргә йөрү катгый тыела.

3.4. Катнашучылар шөгыльләрдә житәкче биремнәрен катгый үтәргә һәм тәртипне сакларга тиешләр.

3.5 Җитәкче рөхсәте белән баланың әти-әнисе дәресләргә керергә мөмкин.

3.6. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге» ел дәвамында планлы чаралар: бәйрәмнәр, фестивальләр, бәйгеләр, отчет концертлар h. б. үткәрә. Әлеге чараларда катнашу шулай ук ижат процессының бер өлеше булып тора, катнашучылар өчен мәҗбүри санала.

3.7. Шөгыльләнү өчен кирәк-яраклар (уку әсбаплары, канцелярия товарлары, махсус кием, аяк киеме һәм башка кирәкле әйберләр) ата-аналар хисабына алына.

3.8. Катнашучылар МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге»нең мөлкәтенә, уку әсбапларына, музыкаль инструментларына, инвентаренә h. б. саклык белән карарга тиеш. Укучылар МАУ«Шатлык» яшьләр үзәге» милкенә зыян китергән очракта, әти-әниләр зыян өчен түләргә бурычлы.

3.9. Залларда, холлда, сыйныфларда һәм бәдрәф бүлмәләрендә тәртип һәм чисталык саклау зарур.

3.10. МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге» администрациясе
— гардеробка тапшырылмаган чит әйберләр өчен,
— фойеда һәм чишену урынында караучысыз калган шәхси әйберләр өчен җаваплылык тотмый.

3.12. Катнашучыларның бурычлары:
— эчке тәртип кагыйдәләрен үтәргә;
— гариза нигезендә кабул ителгән шартларны катгый үтәргә;
— берләшмә җитәкчеләре тарафыннан билгеләнгән барлык биремнәр даими рәвештә үтәргә, дәресләргә йөрергә.

3.13. Коллектив җитәкчеләре:
— МАУ «Шатлык» яшьләр үзәге»ндә расланган планнар һәм шәхси планнар нигезендә дәресләр һәм мәдәни агарту чаралары үткәрәләр.
— дәресләрне көннәре һәм сәгатьләре билгеләнгән челтәр буенча үткәрәләр.
—массакүләм чаралар әзерләгәндә, өстәмә дәресләр һәм репетицияләрне администрация белән килешкән көннәрдә һәм сәгатьләрдә үткәрәләр.
— дисциплинаны һәм кагыйдәләрне бозган берләшмә катнашучыларын коллективтан чыгаралар.